Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2022 елның 4 августыннан №49

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советының «Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренең яңа редакциясендә раслау турында» 2017 елның 19 арелендәге 54 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Ветеринария турында «Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 6 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге советы карарына «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында» 2017 елның 19 апрелендәге 54 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 196 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- хайваннар авыруларын кисәтүне һәм терлекчелек продукциясенең ветеринария-санитария ягыннан куркынычсызлыгын тәэмин итә торган хуҗалык һәм ветеринария чараларын башкарырга, әйләнә-тирә мохитне терлекчелек калдыклары белән пычратуга юл куймаска, шулай ук ел саен яңадан теркәлә торган чорда мәҗбүри дәвалау-профилактика чараларын үткәрергә;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
районы Тәмте  авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
районы Тәмте  авыл җирлеге Советы
рәисе И.А. Зиновьев